

Татар халкы элек-электән **һөнәрче** халык булган. Болгар дәүләте чорында ук ул һөнәрчелек белән шөгыльләнгән. Татарлар арасында кәсеп-һөнәр күп төрле була: агач, сүс һәм мунчала әзерләү һ.б. Агач эшен белүчеләр чана һәм тарантаслары белән бөтен Россиягә танылалар.

Идел буе татарларының XIX һәм XX гасыр башларына 50-150 кәсебе булганлыгы билгеле. Алар агач эшкәртү, урман химиясе, үсемлекләрдән һәм хайваннардан алынган җепселле матдәләр, тире, металл, таш, минераль матдәләр эшкәртү төрләренә бүленгән. Шулар арасында киң таралганы агач эшкәртүгә караган кәсепләр булган. Күмер хәзерләү, дегет һәм сумала кайнату белән дә шөгыльләнгәннәр.

Талчыбык бөгү һөнәре-иң киң таралган һөнәрләрнең берсе. Көнкүрештә талдан кәрҗиннәр, көймәләр, хәтта читәннәр дә ясалган.

Күн эшкәртү һөнәре дә дәрәҗәле булган.



Патша хөкүмәте татарларның корал коюыннан куркып, **тимерчелек** эшеннән тыя. Кыйммәтле металл белән эш итүчеләр материал җитмәү һәм качып эшләү аркасында осталыкның югары ноктасына җитә алмыйлар.


Соңрак авылда тимерчелек эше шактый алга киткән. Төрле хезмәт кораллары, көнкүреш әйберләре-балта, пычак, чүкеч, урак, чалгы, өтерге, келәшчә, йозак, чылбыр



**Хәлиуллин Минегали Хәлиулла улы**



**Шаһиев Хәбибрахман Шаһи улы**



**Нигмәтҗанов Минемулла Нигмәтҗан улы**

һәм күп төрле башка нәрсәләр ясаганнар. Шулай ук калайдан комганнар, чәйнекләр дә эшләнгән.

Тәмәй авылында тимерчеләр Фаттахов Габделбарый, Мәннәнов Мөбәрәкша тимердән көнкүреш кирәк-яракларын коеп куя торган булганнар.

Мәмәшир авылы осталарыннан Шаһиев Хәбибрахман, Нигмәтҗанов Минемулла, Хәлиуллин Минегали, Сафин Әхмәтҗаннарны әйтергә була.

Бәйләү татар халкында традицион рәвештә өйдә башкарыла торган кул эше санала. Татар хатын-кызлары соры һәм көрән төстәге, бизәкләнгән каймалы калын шәлъяулык, оекбаш,





пирчәткә бәйли, соңрак ак төстәге данлыклы юка челтәр яулыклар бәйләгән. Манылмаган сарык йонынннан 5 инә белән оекбаш, бияләй, шарф бәйләү элек тә, хәзерге вакытта да аеруча киң таралган. Авылда күпчелек хатын-кыз бәйләм бәйләгән.

Кызлар тугач та энә-җеп арасында кайнашып үскән. Гаиләләр ишле, дөнья көтәргә акча кирәк. Җәен капка төбенә алып чыгып утырып, ярыша-ярыша бәйләгәннәр. Бигрәк тә **шәл бәйләү** киң таралган булган.



Җиһаншина Менәвәрбикә Җиһанша кызы



Гайфуллина Миңзифа Гайфулла кызы

Шәл өчен яхшы сыйфатлы мамык сатып алганнар. Кәҗә мамыгын иң элек аяларга кирәк булган. Аялау —мамыкны чүпләрдән арындырып, эрләрлек дәрәҗәгә җиткереп чистарту. Аннан җеп эрләп, шәл бәйләгәннәр.

Авылда шәл бәйләүчеләрдән Җиһаншина Менәвәрбикә Җиһанша кызы, Гайфуллина Миңзифа Гайфулла кызы, Саттарова Галимәне атап китәргә була.



Челтәр элдем читәнгә...

Авылда **челтәр бәйләү**челәр дә булган. Челтәр карават кырыйлары, тәрәзә пәрдәләре, күлмәк якалары итеп файдаланылган.

Хатын-кызлар шулай ук ыргак энә белән челтәр ашъяулык, тастымал, чигеш араларын, чаршау, сөлге, алъяпкыч, кулъяулык каймаларын бәйләгән.



Сәмигуллина Миңсылу Минемулла кызы

Йон эшкәртү кәсебе дә татарларда кустарь промышленностенә әверелә. Шул рәвешле киез һәм киез итек әзерләү алга китә. Бу тармакта Мәмәширлеләргә шулай ук тиңнәр булмый.



Итек басу-сезонлы эш. Ул ноябрь ахырыннан февраль азагына кадәр дәвам итә. Итек басу буенча остаз булып җитешкәч, 2-4 кеше башка авыл - шәһәрләргә өязгә чыкканнар (өязгә чыгу дип, элекке вакытта Россиянең өязләргә бүленешеннән чыгып әйтәләр).

Итек басар өчен йонны Башкортстан, Пермь, Курган якларыннан килеп сатканнар яисә итеккә алыштырып биргәннәр. Үзләре кешеләрдән дә җыйганнар.

Сатып алган йон кул белән чүптән чистар-тылган, аннары машинада теттергәннәр. Тетелгән йоннан итек түшәлгән, ягъни формага салынган. Түшәлгән итекләрне казанда кайнаталар. Аннан соң станда басалар. Басканнарын яңадан 20 минут буяуда кайнаталар. Буягач, шомартып, агачтан эшләнгән калыплар белән үлчәмнәрен билгелиләр. (Авылда махсус калыплар гына ясаучы кешеләр дә булган). Мичкә ягып, итекләрне киптерергә куялар, төнгә калдыралар. Иртә белән итекләр инде әзер була.

Авылда итек басу эше белән ныклап, кеше яллап эшләтеп шөгыльләнүчеләр дә булган. Ибраһимов Исмәгыйль Ибраһим улы 4-5 кше тоткан. Бастырган итекләрен үзләре алып барып саткан. Эшчеләренең берсе генә билгеле-Кара Сәми дип йөртелгән. Колхоз төзелү елларында алар Малмыжга күчеп китәләр.

Мәмәшир авылында иң оста, яхшы итеп итек түшәүче Галимова Хәдичә булган. Ул элек шахтада эшләгән, сугыш килеп чыккач, кайтырга мәҗбүр булган. Шулай ук Шаһиев Мотыйгулла, Юнысов Габдрахман, Габбасов Әбүбәкер, Хәлиуллин Минегали, Латыйпов Габбаслар да итек басу осталарыннан саналган.

Тәмәй авылында итек басу осталары Әхмәтҗанов Закирҗан, Шәмсетдинов Сиражетдиннәр булган.

Мәмәширнең безгә билгеле итек басу осталары:



**Галимова Хәдичә Галим кызы**



**Габбасов Әбүбәкер Габбас улы**



**Латыйпов Габбас Латыйп улы**



Язгы һәм көзге эш арасында авыл халкы тегүчелек белән дә шөгыльләнгән. Көзен уңышны җыеп алгач, гадәттә парлап (әтисе һәм улы яки өйрәнчек малай) күрше өязләргә таралганнар, эш тапкан урыннарга тукталып сырып ясалган бишмәтләр, чалбарлар теккәннәр теккәннәр. Шуннан яз башында кайтып налог түләрлек, чәчүлек орлык юнәтерлек акча алып кайта торган булганнар.

Тегүчеләр авыл халкына күлмәкләр, алъяпкычлар, эш бияләйләре тегеп биргәннәр. Мәмәширнең тегүчеләре-ир-атлардан Габитов Гали, Латыйпов Ситдик, хатын-кызлардан Усманова Зәйнәпбану, Абдуллина Фәүзия, Габидуллина Рушания, Сәләхетдинова Бибиямал, Гыйльметдинова Гыйззенур авыл халкына билгеле. Тәмәйдә тегүчелек һөнәре белән шөгыльләнүчеләрдән Шаһабетдинова Закирә, Закирова Минсәйдәләр иң осталардан саналган.



**Габитов Гали**



**Латыйпов Ситдик**



**Усманова Зәйнәпбану**



**Гыйльметдинова Гыйззенур**



**Сәләхетдинова Бибиямал**



**Габидуллина Рушания**

Баш киеме татар милли костюмының аерылгысыз бер өлеше санала. Ирләр баш киеменең эчке һәм тышкы төрләре бар. Эчке төренә түбәтәй, ә тышкысына төрледән-төрле мех яисә чүпрәктән тегелгән шапкалар, эшләпәләр һәм дини баш киеме (чалма) керә. Түбәтәйнең иң борынгы төре дүрт кисәк өлгедән ярымсферик формада тегелгән. Аны формасын саклар



өчен һәм гигиена максатларында (һава йөрсен өчен), юл араларына ат ялы яисә шнур тыгып калдырып, сыра торган булганнар. Яшьләр өчен бик ачык төстәге, бизәкле түбәтәйләр, картлар өчен гадирәкләре тегелгән. Ә түбәтәйләрнең яңарак варианты тигез өсле булган.

Ә хатын-кызларның баш киемнәре татар милли костюмын милли һәм территориаль яктан аерып торучы элемент саналган. Алар яшь үзенчәлекләре турында күп мәгълүмат биргән. Кызлар кия торган баш киеме калфак формасында булган. Чәч үремнәре тигез булып баш киеменнән чыгып торган. Калфакның ак киҗе мамык җепләрдән бәйләнгәне бик популяр булган. Ак



калфакны күбесенчә авыл кызлары кигән, ә шәһәрдә калфакның төрле төстәге ефәк җепләрдән тегелгәне киелгән. Алар бай орнамент яки аппликация белән "колаклы" техникада эшләнгән.

Кияүдәге ханымнарның баш киемнәре кызларныкыннан аермалы буларак, алар хатын-кызның муенын, җилкәсен һәм аркасын тулысынча капларга тиеш булган. Аның өстеннән тагын бер яулык бәйләнгән яки башлык киелгән.

Хатын-кыз баш киеменең аерылгысыз өлеше саналган тастар татарлар яши торган өлкәләрдә дә популяр булган. Ул ак төстәге бәйләвечтән гыйбарәт. Бәйләвечнең очы кызыл төстәге тасма белән бизәлгән.



**Мәктәптә хезмәт дәресләрендә эшләнгән калфак һәм күлмәкләр**



Озын кышкы кичләрдә берәрсенең өендә җыелышып, хатын-кызлар чигү дә чиккән, сөлгеләрне, ашъяулыкларны, кулъяулык һәм баш яулыкларын, чаршауларны татар чигүе белән бизәгән. Чәчәк, яфрак һәм башка үсенте сабакларын сурәтләгән бизәк-ләрдә күбрәк тамбур техникасының "кү-пертеп" чигү, "ишеп" чигү ысуллары кулланылган.



Фәттахова Нәгыймә

Тамбур чигүе белән белән бизәлгән әйберләр кияүгә бара торган кызларның бирнә сандыкларының, көнкүреш һәм интерьерларның аерылгысыз элементлары булып торган. Иң оста **чигүче**ләрдән булып авылда Фәттахова Нәгыймә халык хәтеренә кереп калган. Аның эшен кызы Рәшидә дә дәвам иткән.



Һәр авылда диярлек йорт салу остасы булган, аларны **балта остасы** дип тә йөрткәннәр. XVIII-XIX гасырларда арбалар, чаналар ясау белән дә шөгыльләнгәннәр. Шулай ук мичкә ясау да бик кызыклы шөгыль саналган.

Татарларның кайбер өлеше юкә каерысы әзерләү белән мәшгуль булган. Бу чималдан алар чабаталар, чыпталар ясаганнар. Чыбыктан оста итеп кәрҗиннәр, тырыслар, төрле җиһазлар, тарантаслар үргәннәр.

Агачтан кисеп бизәк ясау белән дә шөгыльләнгәннәр. Агачта нәкыш ую һөнәрендә һәр остазның сере бар. Гадәти үсемлекле нәкыш, буыннан буынга килеп, йорттан йортка күчеп остазлар кулларында камилләшеп, яңа сулыш ала. Электән йортның байлыгы нәкыштан күренгән.

Мәмәшир авылында балта осталарыннан Шакирҗанов Усман, Фәхәров Габделбәрләрне күрсәтергә була.



Фәхәров Габделбәр